**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлеге составына керүче Олы Покровка авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

2023 елның 20 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлегенең Олы Покровка авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключев авыл җирлегенең Олы Покровка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, гражданнарның үзара салымы 1000 сум күләмендә кертелергә тиеш.

2. Җыелган акчаларны Олы Покровка авылы зиратын тәртипкә салуга юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Ключи авыл җирлеге башлыгы А. А. Карпухин**